Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

30.05.2016 ел № 28

Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Иске Казиле авыл җирлеге Советының 24.10.2012 ел, № 48 карары (2014 елның 16 апрелендәге 90 номерлы, 2015 елның 04 апрелендәге 117 номерлы карарлары редакцияләрендә)

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законына һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү сәбәпле, «Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүне (1 нче кушымта) икенче укылышта кабул итәргә.

2. Әлеге карар, гамәлдәге законнар үз көченә керүнең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләрдән тыш, ул игълан ителгән көннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны дәүләт теркәвенә алу өчен Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрергә.

4. Әлеге карарны дәүләт теркәвеннән соң Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм муниципаль берәмлек территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча халыкка җиткерергә:

1) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Иске Казиле авылы, Һади Такташ ур., 4;

2) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Караталга авылы, күпер ур., 5;

3) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Атабай авылы, Үзәк ур., 14;

4) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Караталга авылы, Күпер урамы, 5.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Иске Казиле авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Иске Казиле авыл җирлеге башлыгы,

Кама Тамагы Иске Казиле авыл җирлеге Советы Рәисе И. Х. Сәгъдиев